# КАРАР

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Урмандәй авыл җирлеге составына керүче Урмандәй авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2019 елның 28 ноябре № 9

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Урмандәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Урмандәй авыл җирлеге Советының 2019 елның 5 ноябрендәге 94 нче номерлы «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Урмандәй авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары нигезендә, Аксубай муниципаль районы Урмандәй авыл җирлегендә Урмандәй авылында 2019 елның 28 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:

«Сез 2020 елда Аксубай муниципаль районы Урмандәй авыл җирлеге Урмандәй авылы яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге формада укучы студентлардан тыш, һәм киләсе эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме?:
1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

-торак пункт чикләрендә юл полотносы урнаштыру;

- Урмандәй авылы эчендәге юлларны кышкы чорда карап тоту.

2) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктыртуны да кертеп);

- торак пункт чикләрендә урамнарны яктыртуны оештыру өчен товарлар сатып алу.

3) җирлек зираты территориясен төзекләндерүне оештыру.

- койма алу.

«РИЗА», «КАРШЫ», «ТЫЕЛЫП ТОРДЫЛАР»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашкан 351 граждан кертелгән; тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны - 180 граждан.

Халык җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен 180 граждан тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.

«ТЫЕЛЫП ТОРДЫЛАР» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены түбәндәге карар итте:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Урмандәй авыл җирлеге составына керүче Урмандәй авылында гражданнар җыенын - үткәрелгән дип танырга, халык җыенының ннәтиҗәләрен чын дип танырга.

2. «Сез 2020 елда Аксубай муниципаль районы Урмандәй авыл җирлеге Урмандәй авылы яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннары, көндезге формада укучы студентлардан тыш, һәм киләсе эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме?:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

-торак пункт чикләрендә юл полотносы урнаштыру;

- Урмандәй авылы эчендәге юлларны кышкы чорда карап тоту.

2) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктыртуны да кертеп);

- торак пункт чикләрендә урамнарны яктыртуны оештыру өчен товарлар сатып алу.

3) җирлек зираты территориясен төзекләндерүне оештыру.

- койма алу, - мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны Урмандәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aksubaevo.tatar.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырырга: http://pravo. tatarstan. ru

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Урмандәй авыл җирлеге башлыгы: В. З. Николаев